# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Чукмарлы авыл җирлегенең Нарат-Асты авылы торак пунктында гражданнар
җыены нәтиҗәләре турында

**№ 1**

**13 ноябрь 2020 ел**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 13 ноябрендә 13.00 сәгатьтә, үткәрелгән гражданнар җыенының «2021 елда 200 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Чукмарлы авыл җирлеге Нарат-Асты авылы территориясендә I төркем инвалидлардан; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме:

- Нарат-Асты авылы урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм хезмәт күрсәтү (лампалар,энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру);
- Нарат-Асты авылы җирле әһәмияттәге юлларны кышкы чорда кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары,трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Нарат-Асты авылы өчен газонокосилка (Тремер) сатып алу.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 43 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 27 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен 27 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Чукмарлы авыл җирлегенең Нарат-Асты авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2021 елда 200 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Чукмарлы авыл җирлеге Нарат-Асты авылы территориясендә I төркем инвалидлардан; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме » дигән сорау буенча карар кабул итәргә:

- Нарат-Асты авылы урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм хезмәт күрсәтү (лампалар,энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру);

- Нарат-Асты авылы җирле әһәмияттәге юлларны кышкы чорда кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары,трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- Нарат-Асты авылы өчен газонокосилка (Тремер) сатып алу кабул ителгән.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Чукмарлы авыл җирлегенең Нарат-Асты мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Чукмарлы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Сарман муниципаль районы
Чукмарлы авыл җирлеге башлыгы И.Х.Хадиуллин